**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы комиссия составына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге турында» 2004 елның 31 декабрендәге ПУ-824 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2005 елның 7 декабрендәге ПУ-479 номерлы, 2009 елның 29 гыйнварындагы ПУ-35 номерлы, 2011 елның 7 сентябрендәге ПУ-549 номерлы, 2013 елның 7 мартындагы ПУ-208 номерлы, 2014 елның 15 мартындагы ПУ-275 номерлы, 2015 елның 2 мартындагы ПУ-196 номерлы, 2016 елның 11 мартындагы ПУ-236 номерлы, 2018 елның 21 апрелендәге ПУ-329 номерлы, 2019 елның 8 февралендәге ПУ-89 номерлы, 2020 елның 6 мартындагы ПУ-158 номерлы, 2021 елның 15 апрелендәге ПУ-287 номерлы, 2022 елның 23 апрелендәге ПУ-296 номерлы, 2022 елның 13 октябрендәге ПУ-739 номерлы указлары, Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 22 апрелендәге 251 номерлы һәм 2024 елның 16 мартындагы 202 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы комиссия (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан Р.Ф. Кәлимуллинны, А.В. Крыловны чыгарырга;

б) Комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Камалов Ильяс Фәйзрахман улын – «Татарстан Республикасы Композиторлар берлеге» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисен (килешү буенча);

Сәлахов Рабис Мәгалим улын – «Россия рәссамнар берлеге» бөтенроссия иҗтимагый иҗади оешмасының төбәк бүлекчәсе «Татарстан Рәссамнар берлеге» рәисен (килешү буенча);

в) Комиссия әгъзасы Ф.Р. Бикчәнтәевнең вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Россия Федерациясе Театр әһелләре берлеге (Бөтенроссия театр җәмгыяте)» гомумроссия иҗтимагый оешмасы төбәк бүлекчәсе – «Татарстан Республикасы Театр әһелләре берлеге» рәисе, «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе баш режиссеры (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2025 ел, 22 март
№ 227